Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XVI-5**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 15 феврале

Балык Бистәсе районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенең җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү эше, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен җинаятьчел кул сузулардан яклау, җәмәгатьчлек ышанычын тәэмин итү һәм гражданнарга ярдәм итү буенча күрелә торган чаралар турында

Балык Бистәсе районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге башлыгы Н.Ф.Мостафинның Балык Бистәсе районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенең җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү эше, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен җинаятьчел кул сузулардан яклау, җәмәгатьчлек ышанычын тәэмин итү һәм гражданнарга ярдәм итү буенча күрелә торган чаралар турында чыгышын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының законлылык һәм хокук тәртибе комитетының 2016 елның 15 ноябрендәге “Халык дружиналарын туплау һәм җәмәгать тәртибен саклауны оештыру, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тәртип саклау терәк пунктларын туплау турында” 155 нче карарын, Татарстан Республикасы Хөкүмәте комиссиясенең 2015 елның 13 октябрендәге 3 номерлы хокук бозуларны профилактикалау буенча утырыш беркетмәсенең 2.5 пунктын, 2016 елның 31 мартындагы хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте комиссиясе утырышының 1 номерлы беркетмәсенең 3.5.4 пунктларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү, җинаятьчел кул сузулардан гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча Россия ЭЭМның Балык Бистәсе районы буенча бүлегенең эшен оештыру, җәмәгатьчелек ышанычын тәэмин итү һәм гражданнарга ярдәм итү буенча күрелә торган чараларны игътибарга алырга.

2. Балык Бистәсе районы буенча Россия ЭЭМ бүлегенә тәкъдим итәргә:

2.1)түбәндәгеләр буенча эшне дәвам итәргә:

- район территориясендә тыелган халыкара террорчылык һәм экстремистлык оешмалары вәкилләрен, исламда радикаль агымнар тарафдарларын ачыклау һәм аларга чик кую;

- этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә җинаятьләрне ачыклау;

- биологик ресурсларны куллану белән бәйле җинаятьләрне кисәтү һәм ачу ,шулай ук судан файдалану өлкәсендә;

- корал, сугыш кирәк-яраклары һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнеше өлкәсендә җинаятьләрне ачыклау һәм аларга чик кую;

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында бәйрәм чаралары уздыру чорында җәмәгать тәртибен һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү;

2.2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы белән берлектә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары кизүенең расланган графигы нигезендә гражданнарны җәмәгать тәртибен саклауга җәлеп итүне даими контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы урынбасарына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы эшчәнлеген даими контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының финанс-бюджет палатасына, «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 маддәсен исәпкә алып, 2017 ел дәвамында җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарны  кызыксындыруның махсус фондларын булдыру мөмкинлеген карарга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе                                        И.Г.Вәлиев